ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.03.2019**

Зеленодольск
шәһ.

**КАРАР**
**№ 605**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 1 апрелендәге «Зеленодольск муниципаль районында авыл җирендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшыртуга «2014-2017 елларда һәм 2020 елга кадәрге чорда авыл территорияләренең тотрыклы үсеше» Федераль максатчан программасы буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү алминистратив регламентын раслау турында» 840нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210нчы ФЗ Федераль законга ярашлы, 2017 елның 29 декабрендәге «Гариза бирүченең бер гариза бирү юлы белән бернчә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтү күп функцияле үзәкләрендә күрсәтү мөмкинлеген ныгыту өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 479нчы ФЗ Федераль закон белән, 2018 елның 19 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алганда гражданнарга өстәмә гарантияләр билгеләү өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 204нче ФЗ Федераль закон белән,, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. 2017 елның 1 апрелендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 840нчы карары белән расланган авыл җирендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшыртуга «2014- 2017 елларда һәм 2020 елга кадәр чорда авыл территорияләренең тотрыклы үсеше» Федераль максатчан программасы буенча Административ регламентка кушымтага ярашлы үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә .
2. Әлеге карарны «Интернет» информацион-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.О. Котельниковка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 11 мартындагы
605нче карарына
кушымта

**Административ регламентта үзгәрешләр.**

1.1) Административ регламентның 2нче бүлегендәге 2.5нче пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәтләр Гариза бтрүченең яшәү урыны буенча җирле үзидарә органнары белән элемтә кысасында күрсәтелә. Муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнарның гариза бирүчедән таләп итәргә хокукы юк:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен башта информация җитеп бетмәү сәбәпле баш тартылган документлар бирү, муниципаль хезмәт күрсәтүдә түбәндәге очраклар искәрмә булып тора:

а) муниципаль хезмәт бирү турында беренче гариза биргәннән соң муниципаль хезмәт бирүгә кагылган норматив хокукый актлар таләпләре үзгәрү;

б) элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән һәм муниципаль хезмәт бирүдә яисә муниципаль хезмәт бирү өчен кирәкле документлар кабул итүдә беренче баш тартудан соң мөрәҗәгать итүче биргән документлар һәм муниципаль хезмәтләр бирү турында гаризада хаталар булу;

в) муниципаль хезмәтләр бирүдә яисә муниципаль хезмәтләр бирү өчен кирәкле документлар кабул итүдә беренче тапкыр баш тартканнан соң мәгълүмат үзгәрү яисә документларның срогы чыгу;

г) 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бирүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ Федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.1нче өлешендә каралган, муниципаль хезмәтләр бирү өчен яисә оешма җитәкчесенә кирәкле документлар кабул итүдә беренче тапкыр баш тартканда күп функцияле үзәкнең җитәкчесе, муниципаль хезмәт бирүче орган җитәкчесе имзасы белән язма формада муниципаль хезмәт бирүдә яисә муниципаль хезмәт бирү өчен кирәкле документлар кабул итүдә беренче тапкыр баш тартканда 2010 елның 27 июлендәге 210нчы ФЗ Федераль законның "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бирүне оештыру турында"гы 16нчы маддәсенең 1,1нче өлеше белән каралган оешмалар хезмәткәренең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт бирә торган органның вазифадагы затының хатасы яисә законга каршы гамәле (эшләмәве) фактларын раслаган документлар белән ачыклау гариза бирүчегә хәбәр ителә һәм шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенү сорала.»;

1.2) Административ регламентның V өлешен яңа редакциядә бирергә:

«V. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт бирү буенча яисә аларның хезмәткәрләренең функция башкаручыларның, шулай ук оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт бирә торган органның вазифадагы затының, муниципаль хезмәт бирә торган органның эшенә (эшләмәвенә) һәм карарына риза булмыйча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүе»;

5.1. Муниципаль хезмәт алучыларның муниципаль хезмәт бирү буенча яисә аларның хезмәткәрләренең функция башкаручыларның, шулай ук оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт бирә торган органның

вазифадагы затының, муниципаль хезмәт бирә торган органның эшенә (эшләмәвенә) һәм карарына риза булмыйча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирергә хокукы бар.

5.2. Гариза бирүче шул исәптән шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

5.2.1. 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бирүне оештыру турында" Федераль законның 15.1нче маддәсендә күрсәтелгән запросны, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогы бозылу.

5.2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче риза булмыйча күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең эшенә (эшләмәвенә) һәм карарына судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне, әгәр дә күп функцияле үзәккә 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртипкә ярашлы муниципаль хезмәтләр бирү буенча функция йөкләнгән булса бирә ала.

5.2.3. Гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган эшләр башкару яисә информация яисә документлар таләп итү;

5.2.4. Гариза бирүчедән муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралган документлар кабул итүдән баш тарту;

5.2.5. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән баш тарту каралмаган муниципаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) гариза бирүче судка кадәр (судтан ташы) шикаятен, әгәр дә карарлары һәм эшенә шикаять бирелгән күп функцияле үзәккә 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.3нче өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә ярашлы муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча, ярашлы муниципаль хезмәтләр бирү буенча функцияләр йөкләнгән булса бирә ала;

5.2.6. Гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган түләү таләп итү.

5.2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның вазифадапгы затыннан, күп функцияле үзәктән, күп функцияле үзәк хезмәткәреннән 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.1 нче өлешендә каралган оешмалар, яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт бирүләре нәтиҗәсендә документларда җибәргән хаталарын төзәтүдән, яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозудан баш тартуы. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшләренә (эшләмәвенә) 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.3 нче өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә ярашлы муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча, ярашлы муниципаль хезмәтләр бирү буенча функция йөкләнгән булса, шикаять бирүе.

5.2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү тәртибен яисә срогын бозу;

5.2.9. Әгәр дә нигезләмәре федераль законнар һәм шуларга ярашлы кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, законнар һәм башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган муниципаль хезмәтләрне туктату. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшләвенә (эшләмәвенә), әгәр дә күп функцияле үзәккә, шикаять белдереләсе карарларга һәм эшләвенә (эшләмәвенә) 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.3нче өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә ярашлы муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүе.

5.2.10. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәкле 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы федераль законның 7нче маддәсендәге 1 нче өлешенең 4нче пунктында каралган очраклардан тыш, документларны кабул итүдән беренче баш тартуда булмаган һәм (яисә) дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматны һәм документларны таләп күрсәтелгән очракта гариза бирүче күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә), әгәр дә карарлары һәм эше (эшләмәве) күп функцияле үзәккә 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.3нче өлешендә билгеләнгән тәртипкә ярашлы муниципаль хезмәтләрне күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирә ала.

5.3. Шикаять бирү һәм карау тәртибенә гомуми таләпләр:

5.3.1. Шикаять күп функцияле үзәкнең оештыручысы (алда – күп функцияле үзәк оештыручысы) булып торган халык-хокукый белем бирү җирле үзидарә органына, һәм шулай ук 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.1нче өлешендә билгеләнгән оешмаларга язма формада кәгазьдә, электрон формада бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган җитәкчесенең карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаятьләр «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтле органына бирелә. Күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаятьләр күп функцияле үзәкнең җитәкчесенә бирелә. Күп функцияле үзәкнең карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаятьләр вәкаләте Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вазифадагы затка яисә күп функцияле үзәк оештыручысына бирелә. 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.1нче өлешендә билгеләнгән оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикатьләр шушы оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның вазифадагы заты, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган җитәкчесенең карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаять почта аша, «Интернет» информацион-телекоммуникация челтәрен кулланып, күп функцияле үзәк аша, информацион-телекоммуникация челтәрендә Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайты, дәүләт хезмәтләре бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр региональ порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) аша җибәрелергә һәм шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итүдә алынырга мөмкин. Күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаять почта, «Интернет» информацион-телекоммуникация челтәрен кулланып, күп функцияле үзәк рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә дәүләт һәм муниципаль региональ портал аша, һәм шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итүдә кабул ителергә мөмкин. 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.1нче өлешендә билгеләнгән оешмалар һәм шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаять почта, «Интернет» информацион-телекоммуникация челтәрен кулланып, күп функцияле үзәк рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә дәүләт һәм муниципаль региональ портал аша, һәм шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итүдә кабул ителергә мөмкин.

5.5. Россия Федерациясе башкарма власть федераль органнары, дәүләт корпорацияләре һәм аларның вазифадагы затлары, федераль дәүләт хезмәткәрләре, дәүләт бюджеттан тыш фондлары, 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсендәге 1.1нче өлешендә билгеләнгән оешмалар һәм шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаять, һәм шулай ук күп функцияле үзәк, аның хезмәткәре карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаять бирү һәм карау тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

5.5.1. Әгәр дә муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органнарның вазифадагы затлары, муниципаль хезмәткәрләр карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаять бирү һәм карау тәртибе федераль закон белән билгеләнгән булса, күрсәтелгән шикаятьләрне бирү һәм карау белән бәйле мөнәсәбәтләр өчен 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ федераль законның 11.2, 11,2нче маддәләре неормалары кулланылмый.

5.5.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнарның вазифадагы затлары, яисә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6нчы маддәсенең 2нче өлешенә ярашлы Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган төзелеш өлкәсендә процедураларның тулы исемлегенә кертелгән процедураларга шәһәр төзелеше мөнәсәбәте субъектлары булып торган юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата муниципаль хезмәткәрләр карарларына һәм (яисә) эшенә (эшләмәвенә) шикаять 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы ФЗ федераль законның 11,2нче маддәсендә билгеләнгән тәртиптә шундый затлар тарафыннан монополиягә каршы органга бирелергә мөмкин..

5.6. Шикаятьтә булырга тиеш:

5.6.1. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, муниципаль хезмәткәрнең, күп функцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәрнең, 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсенең 1,1нче өлешендә каралган оешмалар җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәре карарларына һәм эшенә (эшләмәвенә) шикаять бирелүчеләрнең исеме;

5.6.2. Җавап биреләсе гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның тору урыны турында белешмә, шулай ук контакт телефонының номеры (номерлары), электрон почтасының адресы (булса) һәм почта адресы;

5.6.3. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның вазифадагы затның, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсенең 1,1нче өлешендә каралган оешмаларның шикаять бирелгән карарлары һәм эшләре (эшләмәве) турында белешмәләр;

5.6.4. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның вазифадагы затының, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсенең 1,1нче өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм эшләренә (эшләмәвенә) гариза бирүче ризасызлык белдергән исбатлаулар. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең исбатлауларын раслаган документлар (булса), яисә күчермәләре.

5.7.Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органга, күп функцияле үзәккә, күп функцияле үзәк оештыручысына, 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсенең 1,1нче өлешендә каралган оешмаларга, яисә югары тора торган органга килгән шикаять теркәлгән көненнән алып унбиш көн эчендә каралырга тиеш, ә 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсенең 1,1нче өлешендә каралган оешмаларга гариза бирүчедән документлар кабул итүдән баш тартуга һәм киткән хаталарны төзәтүгә бәйле гариза бирүчедән килгән шикаятьләр – теркәлгән көненнән алып биш эш көнендә каралырга тиеш.

5.8. Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

5.8.1. Шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарларны юкка чыгару, документларда муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган килеш алынган түләүләрне кире кайтару формасында канәгатьләндерелә;

5.8.2. Шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.9. Шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивацияләнгән җавап әлеге бүлекнең 5.8нче пунктында күрсәтелгәнчә, карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча язма формада яисә гариза бирүче теләге буенча электрон формада бирелә;

5.9.1. Әгәр дә гариза бирүчегә бирелгән җавапта шикаятьне әлеге бүлекнең 5.9нчы пунктында күрсәтелгәнчә канәгатьләндерелгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган, күп функцияле үзәк яисә 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы ФЗ федераль законның 16нчы маддәсенең 1,1нче өлешендә каралган оешмалар эше турында муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне тиз арада юкка чыгару максатыннан информация бирелә, һәм шулай ук китерелгән уңайсызлыклар

өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәт алу максатыннан мөрәҗәгать итүчегә кирәкле алдагы гамәлләр күрсәтелә.

5.9.2. Гариза бирүчегә шикаятьнең канәгатьләндерелә алмавын тану турында әлеге бүлекнең 5.9нчы пунктында каралган җавап бирелгән очракта кабул ителгән карарларның сәбәбе турында аргументлы аңлатмалар һәм шулай ук кабул ителгән карарларга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә карау нәтиҗәләре буенча шикаятьне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазифадагы затның, хезмәткәрнең административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланса, әлеге бүлекнең 5.3.1нче пунктына ярашлы материаллар кичектерелмичә прокуратура органнарына җибәрелә.

5.11.Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның һәм оешмаларның хокуклары бозылуга шикаятьне карау тәртибен билгеләгән 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы ФЗ федераль законның положениеләре 2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59нчы ФЗ Федераль закон белән көйләнгән мөнәсәбәтләргә кагылмый.